ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«15» апрель 2022 ел № 434

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 21 сентябрендәге 991 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 449-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 21 сентябрендәге 991 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән торглар үткәрмичә генә түләүсез файдалану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән бушлай файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта белән расланган сатулар үткәрмичә генә җир кишәрлеге алу хокукын раслаучы документлар исемлеген түбәндәге эчтәлекле 70 пункт белән тулыландырырга:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 70 | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 22 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокук компаниясе | «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законда каралган функцияләрне һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен | "белгенлек (банкротлык) турында" 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль законда каралган нигезләр буенча җир кишәрлегендә тәгәлләнмәгән төзелеш (капиталь төзелеш объектларын төзү) объектларын төзүне тәгәлләү Россия Федерациясе Җир һәм башка законнарында |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | гавами-хокукый компания эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир кишәрлеге. | билгеләнгән чикләүләр булуга бәйле рәвештә, башкарма хакимиятнең федераль органы, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органы, җирле үзидарә органы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә төзелешкә рөхсәтләр бирүгә вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан мондый чикләүләр булуны раслаганда мөмкин түгел дип раслый торган документлар. |

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Җитәкче Р.Р. Хәмзин